ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.11.2025 № 1274

«2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында халык арасында наркоманияне профилактикалау» муниципаль максатчан программасын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча өстәмә чаралар турында» 2007 елның 18 октябрендәге 13742 номерлы Указын үтәү һәм Нурлат муниципаль районында наркотик чаралар, психотроп матдәләр законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә идарәне камилләштерү максатында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында халык арасында наркоманияне профилактикалау» муниципаль максатчан программасын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат мунципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Г. Гыйниятуллин